**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 16 апрель № 234

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибендә (алга таба – Тәртип):

2 нче пунктка «алга киткән үсеш территориясендә теркәлгән» сүзләреннән соң «һәм эшчәнлеген бары тик шунда гына гына гамәлгә ашыручы» сүзләрен өстәргә;

3 нче пунктта:

«е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;»;

«з» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«з) Гариза бирүченең аерымланган бүлекчәләре булмавы турында һәм Гариза бирүче куллана торган салым түләү системасы хакында салым органыннан мәгълүмат;»;

«и» һәм «к» пунктчаларын төшереп калдырырга;

6 нчы пунктта:

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Гариза бирүченең ул үзенең эшчәнлеген гамәлгә ашырырга планлаштыра торган алга киткән үсеш территориясеннән читтә урнашкан филиалы, вәкиллеге яки башка аерымланган бүлекчәләре булу.»;

«г» пунктчасын төшереп калдырырга;

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Бизнес-план анализы түбәндәге күрсәткечләргә мөнәсәбәтле гамәлгә ашырыла:

а) күрсәтелгән инвестицияләр күләме;

б) үз акчасы һәм заем акчасы, аларның чагыштырмасы;

в) инвестицион проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә бирелә торган преференцияләр күләме (дәүләт бюджеттан тыш фондларга һәр салым һәм иминият кертеме буенча);

г) Килешү төзегәннән соң 10 ел эчендә инвестицион проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә кертеләчәк дәүләт бюджеттан тыш фондларга салымнар һәм иминият кертемнәре суммасы;

д) Килешү төзегәннән соң 10 ел эчендә булдырылган инвестицион проектка өстәмә кыйммәт;

е) булдырыла торган эш урыннары саны;

ж) норматив документларның максатларына һәм бурычларына туры килгән башка икътисадый һәм социаль күрсәткечләр.»;

12 нче пунктка «Гариза бирүченең инвестицион проектын гамәлгә ашыру максатка ярашлы булу (булмау) турындагы» сүзләреннән соң «норматив документлар белән расланган Россия Федерациясе монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелә торган алга киткән үсеш территорияләре резидентлары тарафыннан тормышка ашырыла торган инвестицион проектларга булган таләпләргә туры килүе хакындагы» сүзләрен өстәргә;

14 нче пунктта «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары» сүзләренә алмаштырырга;

15 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Комиссия Комиссия рәисеннән – Татарстан Республикасы Премьер-министрыннан, Комиссия рәисе урынбасарыннан – Татарстан Республикасы икътисад министрыннан, Комиссия секретареннән – башкарма комитет вәкиленнән һәм Комиссия әгъзаларыннан тора.»;

түбәндәге эчтәлекле яңа $28^1$ нче пункт өстәргә:

«$28^1$. Төзелгән Килешү нигезендә гамәлгә ашырыла торган инвестицион проектны тормышка ашыру эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек өлешендә Резидент тарафыннан керемнәр (чыгымнар), мөлкәт, җир кишәрлекләре һәм эш урыннарының аерым исәп-хисабы гамәлгә ашырыла.»;

Тәртипкә 1 нче һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр);

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү формасын (бертип формасын) яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\234.doc

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган моношәһәрнең алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 апрель, 234 нче карары редакциясендә)

Форма

**Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган моношәһәрнең алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гариза**

«_______________________________________________________»
алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе исеме
алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә
эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә
ГАРИЗА

____________________________________________________ муниципаль берәмлеге террито-
муниципаль берәмлек исеме

риясендә теркәлгән һәм һәм эшчәнлеген бары тик шунда гына гына гамәлгә ашыручы, ____________________________________________________________ нигезендә эш итүче ____________________________________________________________________ йөзендә
(вазыйфа, Ф.И.Ат.и.)

_____________________________________________________________________________
(юридик зат исеме)

«________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гариза җибәрә һәм «Россия Федерациясендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 ел, 29 декабрь, ФЗ-473 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче карары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «____________________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» _______ ел, _________, ______ карары таләпләренә җавап биргән инвестицион проектны тормышка ашыру ниятен раслый.

Гаризага таләп ителә торган материаллар теркәлә. Мәгълүматларның дөреслеген гарантиялим.

Кушымта:

Җитәкче _______________ __________________ /_________________
(дата) (имза) (Ф.И.Ат.и.)

М.У.*

---

* Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта.

_________________________

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган моношәһәрнең алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 апрель, 234 нче карары редакциясендә)

Форма

## Инвестицион проект паспорты

Гариза бирүче турында мәгълүмат:

| | |
|---|---|
| Тулы һәм кыскартылган исеме | |
| Оештыру-хокукый формасы | |
| Теркәү датасы | |
| Теркәү урыны | |
| Гамәлдә урнашкан урыны | |
| Милекчеләр (моношәһәрнең шәһәр төзү оешмасы белән бәйләнеше булмау турындагы мәгълүматны кертеп) | |
| ОКВЭД буенча кодларны күрсәтеп, төп икътисадый эшчәнлек төрләре | |
| Соңгы 3 елга эшчеләрнең исемлек буенча уртача саны | |
| Дәүләт ярдәме булу/булмау һәм аның формалары | |
| Махсус салым режимын куллану | |
| шәхси тәңгәлләштерү саны (ИНН) | |
| төп дәүләт теркәү саны (ОГРН) | |
| исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) | |
| Элемтәгә керү өчен зат | |
| Телефон | |
| Электрон почта адресы | |

Инвестицион проект турында мәгълүмат:

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Инвестицион проект исеме (алга таба – ИП) | |
| 2 | ОКВЭД нигезендә ИП буенча икътисадый эшчәнлек төре | |
| 3 | ИП гамәлгә ашыру урыны | |
| 4 | ИП характеры («нульдән» төзү, төзекләндерү, модернизацияләү, гамәлдәге производствода яңа продукция чыгару, гамәлдәге производствоны киңәйтү, башкасы) | |
| 5 | ИП максаты һәм, табигый һәм кыйммәти чагылышта проектның еллык куәтен күрсәтеп, асылының кыскача тасвирламасы | |
| 6 | Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш бурычларына, тармак үсеш | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | стратегияләре (программалар, концепцияләр) өстенлекләренә ИП туры килүен нигезләү, аларны раслау турында тиешле норматив хокукый актларны күрсәтеп | | |
| 7 | ИП гамәлгә ашыру вакытлары (төп капиталга инвестицияләр кертү чоры), шул исәптән төп этаплары: | | |
| 7.1 | инвестицияләр алды тикшеренүләре, проект документларын/бизнес-план эшләү | | |
| 7.2 | килештерү һәм рөхсәт бирү документларын алу | | |
| 7.3 | төзү | | |
| 7.4 | җиһазлар сатып алу һәм кайтарту | | |
| 7.5 | проектны башлау (эксплуатациягә кертү) | | |
| 7.6 | проект куәтенә чыгу | | |
| 8 | ИП эшләнеш дәрәҗәсе (ИП гамәлгә ашыру кирәклеге турында карар кабул итү датасы һәм дәрәҗәсе, проект документларының әзерлек дәрәҗәсе (дәүләт экспертизасы бәяләмәләре булу), ИП гамәлгә ашыру буенча элегрәк үткәрелгән һәм хәзерге вакытта тормышка ашырыла торган чаралар, ИП гамәлгә ашыру кысаларында күрсәтелгән дәүләт ярдәме формасы булу) | | |
| 9 | ИП гомуми кыйммәте (ӨКС белән), млн.сум, шул исәптән | | |
| 9.1 | алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты статусын алганнан соң планлаштырыла торган капиталь кертемнәр күләме (ӨКСнан башка), млн.сум | | |
| 10 | ИП финанслауның тәэмин ителеш дәрәҗәсе (финанслауның документлар белән расланган чыганаклары), ИП гомуми кыйммәтеннән % | | |
| 11 | Инвестицион чыгымнар структурасы һәм аларны үзләштерү дәрәҗәсе: | Бәясе, мең сум | Планлаштырылган күләмнән кертелгән акча өлеше, % |
| 11.1 | капиталь чыгымнар, шул исәптән: | | |
| 11.1.1 | проектлаштыру | | |
| 11.1.2 | җир сатып алу | | |
| 11.1.3 | төп чаралар сатып алу | | |
| 11.1.4 | төзү-монтажлау эшләре | | |
| 11.1.5 | җиһазлар сатып алу | | |
| 11.1.6 | инвестицион фазада башка чыгымнар | | |
| 11.2 | әйләнештәге капиталга инвестицияләр | | |
| 12 | ИП тормышка ашыру җир кишәрлегенең кадастр саны һәм мәйданы (булган очракта) | | |
| 13 | ИП өчен таләп ителә торган инфраструктура, ресурслар һәм аларның булуы, шул исәптән: | | |
| 13.1 | инвестицион проектны тормышка ашыру өчен кирәкле җир кишәрлекләре һәм мөлкәт, шулай ук аларның булуы | | |
| 13.2 | гариза бирүченең энергия алу җайланмаларының ялгана торган кирәкле куәте күләме, җылы- | | |

| | | |
|---|---|---|
| | лык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү һәм су белән тәэмин итү хезмәтләре күрсәтү өчен файдаланыла торган кирәкле ресурсларга (шул исәптән салкын һәм кайнар су, челтәрдәге газ һәм җылылык энергиясе), шулай ук инвестицион проектны тормышка ашыру өчен кирәкле башка ресурсларга мөнәсәбәтле ялгана торган кирәкле йөкләнеш төрләре, күләмнәре һәм планлаштырыла торган зурлыгы, аларның булуы | |
| 14 | Дәүләт һәм үстерү институтлары тарафыннан ярдәм күрсәтүнең күздә тотылган формасы | |
| 15 | ИПның финанс-икътисадый, бюджет һәм социаль нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре: | |
| 15.1 | чиста дисконтлы табыш (NPV), млн.сум | |
| 15.2 | чыгымнар каплануның гади вакыты, ел | |
| 15.3 | чыгымнар каплануның дисконтлы вакыты, ел | |
| 15.4 | табышларның эчке нормасы (IRR), % | |
| 15.5 | проект куәтенә чыкканда, шулай ук тулаем проект буенча, бер елга ИП тарафыннан булдырыла торган өстәмә кыйммәт (салым салганчы булган табыш, бурыч йөкләмәләре буенча процентлар түләү һәм амортизация буенча түләүләр + хезмәткәрләрнең кушылган эш хакы + аренда түләве), млн.сум | |
| 15.6 | ИП проект куәтенә чыкканда, шулай ук тулаем проект буенча, бер елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына салым керемнәре күләме, мең сум | |
| 16 | Булдырыла торган эш урыннары саны, берәмлек, шул исәптән: | |
| 16.1 | алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты статусын алганнан соң булдырыла торган, берәмлек | |
| 16.2 | чит илдән килгән эшчеләр биләгән, берәмлек | |
| 17 | Моношәһәрнең шәһәр төзү оешмасына яки аның бүлендек предприятиеләренә хезмәтләр күрсәтүдән, товарлар реализацияләүдән керемнең инвестицион проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә җитештерелгән (күрсәтелгән) товарлар (хезмәтләр) реализацияләүдән кергән барлык керемгә карата чагыштырмасы, % | |
| 18 | ИП проект куәтенә чыкканда, уртача айлык эш хакы, сум | |

Җитәкче __________________ _____________________ /_________________

(дата) (имза) (Ф.И.Ат.и.)

М.У.*

------------------------------

* Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта.

## Инвестицион проектның төп күрсәткечләре

| Т/с | Күрсәткеч | Годы | | | | | | | | | | | | | | | Бар-лыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 нче | 2 нче | 3 нче | 4 нче | 5 нче | 6 нчы | 7 нче | 8 нче | 9 нчы | 10 нчы | 11 нче | 12 нче | 13 нче | 14 нче | 15 нче | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 |
| 1 | **Даими эш урыннары булдыру планы, кеше** | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2 | **ИП гамәлгә ашыру еллары буенча инвестицияләр кертү, млн.сум, ӨКС исәпкә алмаганда, шул исәптән:** | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1 | үз акчасы (керем, амортизация) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.2 | җәлеп ителә торган акча, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.2.1 | банклар кредитлары | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.2.2 | федераль бюджет акчасы | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.2.3 | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.3 | чит ил инвестицияләре, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.3.1 | туры чит ил инвестицияләре | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3 | **Табыш күләме, мең сум** | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4 | **Керем күләме, мең сум** | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5 | **Иминият кертемнәре, мең сум** | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |
| 5.1 | ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.2 | ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш[1] | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6 | **Өстәмә кыйммәткә салым, мең сум** | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7 | **Табышка салым, мең сум** | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |
| 7.1 | федераль бюджетка, шул исәптән: | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |
| 7.1.1 | ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш[2] | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.1.2 | ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш[3] | | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7.2 | Татарстан Республикасы бюджетына, шул исәптән: | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |
| 7.2.1 | ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш [4] | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.2.2 | ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш [5] | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8 | **Физик затларның керемнәренә салым (НДФЛ) барлыгы, мең сум** | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.1 | Татарстан Республикасы бюджетына | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.2 | муниципаль берәмлек бюджетына | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9 | **Оешмалар мөлкәтенә салым, мең сум** | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |
| 9.1 | ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9.2 | ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш [6] | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 10 | **Җир салымы, мең сум** | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |
| 10.1 | ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 10.2 | ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш [7] | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 11 | **Транспорт салымы, мең сум** | | | | | | | | | | | | | | | | |
| **Бюджетлар дәрәҗәләре буенча салым түләүләре һәм социаль түләүләр буенча барлыгы** | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 12 | Иминият кертемнәре буенча алынып бетмәгән керемнәр (5.1 п.– 5.2 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 13 | Федераль бюджетка ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш (6 п. + 7.1.1 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 14 | Федераль бюджетка ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш (6 п.+ 7.1.2 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 15 | Россия Федерациясенең алынып бетмәгән керемнәре (13 п.– 14 п.+ 12 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16 | Россия Федерациясе буенча сальдо (14 п.– 15 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 17 | Татарстан Республикасы бюджетына ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш (7.2.1 п.+ 8.1 п.+ 9.1 п.+ 11 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 18 | Ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш (7.2.2 п.+ 8.1 п.+ 9.2 п.+ 11 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 19 | Татарстан Республикасының алынып бетмәгән керемнәре (17 п.– 18 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 20 | Татарстан Республикасы буенча сальдо (18 п.– 19 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 21 | Муниципаль берәмлек бюджетына ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш (8.2 п.+ 10.1 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 22 | Муниципаль берәмлек бюджетына ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш (8.2 п.+ 10.2 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 23 | Муниципаль берәмлекнең алынып бетмәгән керемнәре (21 п.– 22 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 24 | Муниципаль берәмлек буенча сальдо (22 п.– 23 п.) | | | | | | | | | | | | | | | | |

[1] Салым суммасы 7,6 процент ставкасы буенча исәпләнә. Әлеге ташлама юридик зат алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе (алга таба – АКСИҮ территориясе) резиденты статусын алган көннән 10 ел дәвамында тарала. Иминият кертемнәренең ташлама тарифлары әлеге статусны АКСИҮ территориясен төзегән көннән 3 елдан да соңга калмыйча алган резидентларга мөнәсәбәтле кулланыла.

[2] 2 процент күләмендәге салым ставкасы буенча исәпләнгән салым суммасы.

[3] Салым исәбе мәгълүматлары нигезендә АКСИҮ территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешүләрне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән беренче табыш алынган салым чорыннан башлап, 5 салым чоры дәвамында 0 процент күләмендә салым ставкасы.

[4] 18 процент күләмендәге салым ставкасы буенча исәпләнгән салым суммасы.

[5] Салым исәбе мәгълүматлары нигезендә АКСИҮ территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешүләрне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән беренче табыш алынган салым чорыннан башлап, беренче 5 салым чоры дәвамында салым ставкасы – 5 процент күләмендә, киләсе 5 салым чоры дәвамында – 10 процент күләмендә.

[6] Оешма балансында исәпкә алына торган мөлкәткә карата ставка мөлкәтне исәпкә алган вакыттан 10 ел дәвамында 0 процент күләмендә билгеләнә.

[7] Ставка 0 процент күләмендә билгеләнә.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Җитәкче | ____________________ | ______________________ / | __________________ |
| | (дата) | (имза)<br>М.У.* | (Ф.И.Ат.и.) |

-------------------------------

* Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта.

_______________________________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 апрель, 234 нче карары редакциясендә)

Форма

**«____________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү**

______________ «___» ___________ 20__ ел

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә эш итүче _____________________________________ йөзендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык), Низамнамә нигезендә эш итүче _____________________________________ башкарма комитеты җитәкчесе йөзендә Татарстан Республикасы «________________________» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) һәм ___________________ нигезендә эш итүче _____________________________________ йөзендә алга таба «Резидент» дип аталучы _________________________________,
(юридик зат исеме)
бергә – «Яклар», аерым алганда «Як» дип аталучылар, «Россия Федерациясендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 ел, 29 декабрь, ФЗ-473 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче карары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «______________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» 201__ ел, ___________, _______ карары (алга таба – норматив документлар) нигезендә әлеге «___________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешүне (алга таба – Килешү) түбәндәгеләр турында төзедек:

1.1.1 Килешү предметы

1.1. Резидент тарафыннан кертелгән Килешү төзүгә гариза, аңа теркәлгән

бизнес-план һәм Килешүгә 1 нче кушымтада китерелгән инвестицион проектны тормышка ашыру планы нигезендә, Килешүдә һәм норматив документларда күздә тотылган шартларда, «________________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә (алга таба – алга киткән үсеш территориясе) _________________________ кадастр санлы (кадастр саннардагы) җир кишәрлегендә _________________________________ икътисадый эшчәнлек төрләре буенча «_________________________________» яңа инвестицион проектын (алга таба – инвестицион проект) тормышка ашыру йөкләмәсен Резидент үз өстенә ала.

2.1.1. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

2.1. Килешү ____________ кадәр вакытка төзелә һәм Яклар тарафыннан кул куелган көннәнн үз көченә керә.

2.2. Килешүнең гамәлдә булу вакыты Якларның ризалыгы буенча алга киткән үсеш территориясе гамәлдә булган чордан артык булмаган вакытка озайтылырга мөмкин.

3.1.1. Якларның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Министрлык, Башкарма комитет һәм Резидент Килешүнең тулы күләмдә үтәлүенә булышлык күрсәтү йөкләмәсен үз өстенә алалар, һәм моның өчен кирәк булган очракта Килешүнең үтәлешенә каршылыклар тудырган хәлләр турында бер-берсенә хәбәр итәчәкләр һәм аның үтәлеше буенча килешенгән гамәлләр кылачаклар.

3.2. Министрлык, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче карары белән расланган Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары реестрын алып бару кагыйдәләре нигезендә, Резидентның Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары реестрына (алга таба – Реестр) кертелүенә булышлык күрсәтү йөкләмәсен үз өстенә ала.

3.3. Башкарма комитет инвестицион проектның гамәлгә ашырылуына булышлык күрсәтү, шул исәптән мәнфәгатьле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары белән берлектә, Резидент тарафыннан инвестицион проектның үтәлешенә булыша торган норматив хокукый актларны әзерләүне һәм үз вакытында кабул итүне тәэмин итү йөкләмәсен үз өстенә ала.

3.4. Министрлык һәм Башкарма комитет Резиденттан Килешүдә каралган йөкләмәләрнең үтәлеше барышы турында мәгълүмат соратып алырга хокуклы.

3.5. Резидент түбәндәгеләргә бурычлы:

3.5.1. Килешү шартларын һәм норматив документлар нигезләмәләрен үтәргә;

3.5.2. Килешүгә теркәлгән 1 нче кушымтада күздә тотылган инвестицион проектның төп күрсәткечләре үтәлешен тәэмин итәргә. Инвестицион проектны тормышка ашыруның беренче елында һәм инвестицион проект буенча тулаем минималь күләмнәрне үтәү шартында һәр күрсәткеч буенча 25 процентка кадәр тайпылышлар рөхсәт ителә;

3.5.3. Инвестицион проектны тормышка ашыруга ӨКС исәпкә алмыйча _____________________________________________ (суммасы сүзләр белән) млн.сум күләмендә капитал кертемнәре (шулардан кимендә 5 (биш) млн.сум Килешүне төзегән көннән башлап беренче елда) җәлеп итәргә, шул исәптән:

3.5.3.1. Үз акчасы _______________________ (суммасы сүзләр белән) млн.сум күләмендә, яки инвестицион проектның гомуми кыйммәтеннән ___ процент;

3.5.3.2. Җәлеп ителгән акча _______________ (суммасы сүзләр белән) млн.сум күләмендә, яки инвестицион проектның гомуми кыйммәтеннән ___ процент;

3.5.4. Проектны тормышка ашыру барышында кимендә ____________ (саны сүзләр белән) яңа эш урыны, шул исәптән кимендә 20 (егерме) яңа эш урынын Килешүне төзегән көннән беренче ел дәвамында булдыруны тәэмин итәргә, шулай ук Килешүгә кул куйган көнгә Резидентның исемлек буенча уртача хезмәткәрләр санының кимендә 90 процентын Килешү көчендә булу чорында саклауны тәэмин итәргә;

3.5.5. Инвестицион проектны тормышка ашыру процессында Резидент хезмәткәрләренә уртача эш хакын Татарстан Республикасы буенча уртача тармак эш хакыннан түбән булмаган яки ________________________ муниципаль берәмлеге буенча уртача эш хакыннан түбән булмаган күләмдә тәэмин итәргә.

3.5.6. Инвестицион проект объектлары төзелешен бизнес-планда һәм проект документларында каралган тәртип, шартлар һәм вакытлар нигезендә тормышка ашырырга;

3.5.7. Министрлыкка һәм Башкарма комитетка квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр түбәндәгеләрне кертергә:

3.5.7.1. Килешүгә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча Килешүне үтәү турында хисап мәгълүмат;

3.5.7.2. Министрлык раслаган форма буенча инвестицион проектны тормышка ашыру барышы турында хисап мәгълүмат;

3.5.7.3. Килешүнең 4.1.1 нче пунктында каралган хәлләр булмау турында белешмә;

3.5.8. Министрлыкка ел саен 1 майга кадәр Татарстан Республикасының тармак министрлыгы белән килештерелгән, Министрлык раслаган форма нигезендә киләсе елга инвестицион проект буенча Резидент эшчәнлеге программасын кертергә;

3.5.9. Килешүне тормышка ашыру эшчәнлеген һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашырганда керемнәр (чыгымнар), мөлкәт, җир кишәрлекләре һәм эш урыннарының аерым исәп-хисабы гамәлгә ашырырга;

3.5.10. Килешүнең 4.1.1 нче пунктында күздә тотылган хәлләр килеп чыгу

турында Министрлыкка һәм Башкарма комитетка әлеге хәлләр барлыкка килгән көннән 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;

3.5.11. Резидент буларак үз хокукларыңны һәм бурычларыңны башка затларга тапшырмаска;

3.5.12. Министрлыкка һәм Башкарма комитетка Килешү шартларының үтәлешен тикшерүдә тоту өлешендә булышлык күрсәтергә, шул исәптән Министрлык һәм Башкарма комитет вазыйфаи затларының Резидентныкы булган инфраструктура объектларына һәм алга киткән үсеш территориясендә урнашкан объектларга тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә;

3.5.13. Министрлыкка һәм Башкарма комитетка тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны тиешле сорату алган көннән 5 (биш) эш көне эчендә язма рәвештә кертергә.

3.6. Иминият кертемнәре, салымнар һәм җыемнар турындагы норматив документлар һәм законнар нигезендә Резидентка түбәндәге преференцияләр бирелә:

| Салым, иминият кертемнәре төре исеме | Ставка (тариф) | Преференцияләр суммасы, мең сум | Преференцияләр бирү вакытлары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

Әлеге преференцияләр суммалары якынча булып тора.

Иминият кертемнәре, салымнар һәм җыемнар турындагы норматив документлар һәм законнар нигезендә Резидентка каралган преференцияләр бары тик Килешүне тормышка ашыру эшчәнлеген гамәлгә ашырганда гына бирелә, шул исәптән түбәндәгеләр буенча:

оешмалар керемenә салым буенча – Килешү нигезендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган керем өлешендә,

оешмалар мөлкәтенә салым буенча – Килешү нигезендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен яңадан булдырылган яки сатып алынган мөлкәткә мөнәсәбәтле,

җир салымы буенча – Килешү нигезендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир кишәрлекләренә карата,

Россия Федерациясе Пенсия фондына, Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондына, Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондына иминият кертемнәре буенча – Килешү нигезендә тормышка ашырыла торган инвестицион проектта мәшгуль булган Резидент хезмәткәрләренә карата.

3.7. Преференцияләр бирү күрсәтелгән ставкалар (тарифлар) нигезендә хисап чоры йомгаклары буенча, бухгалтерлык һәм салым хисаплылыгында чагылдырылган Резидент эшчәнлегенең факттагы күрсәткечләреннән чыгып гамәлгә ашырыла.

4. Килешүнең гамәлдән чыгу шартлары

4.1. Килешүне өзү Якларның ризалыгы яки суд карары буенча рөхсәт ителә. Якларның берсе Килешү шартларын җитди бозуга, шартларның шактый үзгәрүенә бәйле рәвештә яки норматив документларда каралган башка нигезләрдә Килешү башка Як таләбе буенча суд тарафыннан өзелә ала.

4.1.1. Резидентның Килешү шартларын җитди бозу булып түбәндәгеләр тора:

а) Резидентның норматив документларда каралган таләпләргә туры килмәве;

б) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына юридик зат – Резидент ябылу процессында тора дигән язма кертү;

в) Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә үзгәртеп оештыру юлы белән юридик затның – Резидентның эшчәнлеген туктатуы;

г) законлы көченә кергән юридик затны – Резиденты банкрот дип тану турында суд карары;

д) Килешүдә каралган инвестицион проект параметрларның 25 проценттан күбрәк яки норматив документлар белән расланган, Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары гамәлгә ашыра торган инвестицион проектларга булган таләпләрне үтәп, аны тормышка ашыру мөмкинлеген калдырмый торган үзгәрүе;

е) ел йомгаклары буенча, рөхсәт ителгән тайпылышларны исәпкә алып, Килешүгә 1 нче кушымтада күрсәтелгән бер күрсәткечне булса да үтәмәве;

ж) Резидентның Килешү шартларын үтәмәве.

4.2. Резидент Килешүне вакытыннан алда өзү турында хәбәрнамә алган көннән Килешү өзелгән булып санала. Шул ук вакытта Килешүнең 3.6 нчы пунктында күрсәтелгән преференцияләрне бирү түләүләрнең Килешү өзелгән хисап чоры башыннан туктатыла.

4.3. Килешүне өзгән вакытта Резидент Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «______________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» 201__ ел, __________, ______ карары белән билгеләнгән капитал кертемнәренең минималь күләме һәм яңа даими эш урыннарының минималь саны өлешендә таләпләрне үтәмәгән булса, Резидент Килешүне өзгән көннән соң бер ай эчендә Килешү нигезендә барлык элек түләнмәгән салымнар суммасын, шулай ук Килешүне төзегәннән алып өзгәнгә кадәрге чорда гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының яңадан финанслау ставкасыннан чыгып, Килешүнең гамәлдә булган һәр календарь көне өчен салынган салымнарның түләнмәгән суммасына тиешле пенялар һәм процентлар түләргә тиеш.

4.4. Килешү түбәндәге очракларда гамәлдән чыгарыла:

4.4.1. Килешү төзелгән вакыт чыккач.

4.4.2. Килешүне өзгән очракта.

4.4.3. Алга киткән үсеш территориясенең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта.

## 5. Килешү Якларының җаваплылыгы

5.1. Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен җавап тота.

5.2. Килешү өзелгән очракта, аны үтәүгә бәйле рәвештә Резидент күтәргән чыгымнар кайтарылмый.

5.3. Килешү буенча йөкләмәләрен үтәмәгән яки аларны тиешенчә үтәмәгән Резидент шулай ук Россия Федерациясе законнарында һәм Килешүдә каралган башка төрле җавап тота.

5.4. Әгәр Килешү буенча йөкләмәне үтәмәү каршы тора алмаслык көч аркасында килеп чыккан булса, Яклар Килешү шартларын үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.

## 6. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

6.1. Яклар арасында барлыкка килергә мөмкин булган Килешү буенча барлык бәхәсләр һәм каршылыклар Яклар тарафыннан дәгъвалар тәртибендә (судка кадәр) хәл ителәчәк.

6.2. Бәхәсләрне сөйләшүләр юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, Яклар аларны суд каравына җибәрә

## 7. Йомгак нигезләмәләр

7.1. Килешүдә каралмаган барлык очракларда Яклар Россия Федерациясе законнарына таянып эш итә.

7.2. Килешүгә кертелә торган барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр алар язма рәвештә эшләнде һәм аларга барлык Яклар кул куйды дигән шартта гына хакыйкый була.

7.3. Килешү тигез юридик көчкә ия 7 (җиде) нөсхәдә төзелде.

7.4. Килешүдә күрсәтелгән барлык вакытлар, әгәр башкасы ачык күрсәтелмәсә, календарь вакытлары була.

7.5. Барлык хәбәрнамәләр һәм хәбәрләр язма рәвештә җибәрелергә тиеш. Әгәр хәбәрләр заказлы хат буларак, факс буенча җибәрелсә яки Якларның почта адреслары (факс номерлары) буенча алу турында шәхси имза куйдырып тапшырылса, алар тиешле рәвештә үтәлгән дип санала.

7.6. Резидентның алга киткән үсеш территориясеннән читтә филиаллары һәм вәкиллекләре булырга тиеш түгел.

7.7. Резидент Килешү буенча үз хокукларын һәм бурычларын башка затка бирергә хокукы юк.

7.8. Килешүгә түбәндәгеләр теркәлә һәм аның аерылгысыз өлешләре булып санала:

бизнес-план;

Килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия карары (беркетмәсе) күчермәсе;

______________________________________________.
(кушымтаның башка материаллары)

| | | |
|---|---|---|
| **Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы** | **Татарстан Республикасы «______________________» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты** | **Резидент:** |
| ___________________________ | ________________________ | _______________________ |
| «___»__________20___ ел | «___»____________20___ел | «___»_________20___ел |

______________________________________________

«____________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында 2016 ел, _________, ______ килешүгә 1 нче кушымта

Форма

**«____________________________________________»**
**инвестицион проектын тормышка ашыру планы**

| Күрсәткечләр | Беренче ел | | | | Икенче ел | | | | n-нчы ел | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | I кв. | II кв. | III кв. | IV кв. | I кв. | II кв. | III кв. | IV кв. | I кв. | II кв. | III кв. | IV кв. |
| 1. Инвестицион проектны тормышка ашыра башлаганнан капитал кертемнәре күләме, мең сум, ӨКСнан башка | | | | | | | | | | | | |
| 3. Инвестицион проектны тормышка ашыра башлаганнан яңа эш урыннары булдыру, берәмлек | | | | | | | | | | | | |

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы**

_____________________
«___»___________20___ ел

**Татарстан Республикасы «_______________________» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты**

_____________________
«_____»____________20___ел

**Резидент:**

_____________________
«____»_________20___ел

«_____________________________»
алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында 2016 ел, _________, ______ килешүгә 2 нче кушымта

Форма

«_______________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешү йөкләмәләрен үтәү хакында мәгълүмат

_____________________________________________________

(Резидент исеме)

_____________________________

(хисап чоры)

1. Инвестицион проект исеме _______________________________________________
2. Инвестицион проектны гамәлгә ашыра башлаган вакыт_______________________
3. Инвестицион проект буенча капитал кертемнәре күләме ______________________
4. Инвестицион проект буенча исемлек нигезендә уртача сан ___________________, шул исәптән инвестицион проект буенча яңа эш урыннары булдыру ______________

| Т/с | Күрсәткечләр | Хисап чорына план | Факт |
|---|---|---|---|
| 1 | Булдырылган даими эш урыннары саны, кеше | | |
| 2 | Капитал кертемнәре күләме, мең сум, ӨКСнан башка | | |

Җитәкче ________________ ___________________ /_______________
(дата) (имза) Ф.И.Ә.И.

М.У.*

------------------------------
* Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта.